# Малайларга, кызларга@.RU

Малайларга, кызларга@.

## *Айлинаның, Ильвинаның уңышларына сөенәбез*

Әдәбият белән якыннан кызыксынучы, әсәрләр укырга яратучы укучылар дәрестә башкалардан аерылып тора. Андыйлар тирән фикер йөртә, сорауларга төгәл һәм тулы җавап бирә, кызыксынучан, аралашучан, максатчан була. Шундый укучыларымның берсе – Айлина Котлыбаева белән таныштырасым килә.

Айлина безнең мәктәптә укый башлагач та үз-үзен тотышы, тирән белеме, тырышлыгы белән сыйныфташларында гына түгел, укытучыларда да үзенә карата уңай мөнәсәбәт уятты. Ул Яңа Юлдаш мәктәбеннән килде. Әдәбиятны сөюче кыз анда укыганда ук матур гына уңышлар күрсәтеп өлгергән. Талбазы лицеенда укый башлаган елны ук татар теле һәм әдәбияты буенча мәктәп олимпиадасында 1нче урын алды. Айлинаның күңелендә туган телебезгә һәм әдәбиятка тирән сөю уяткан, беренче иҗат орлыклары салган әти-әнисенә зур рәхмәт җиткерәсе килә.

Олимпиадаларда, конкурсларда катнашырга омтылган укучылар белән, нигездә, дәрестән соң әзерләнәбез. Ильмира белән шөгыльләнү күңелгә аеруча канәгатьлек өсти, чөнки ул кирәкле әсәрләрне вакытында укып, язучылар иҗаты белән кызыксынып бара. Өйдә дә китап укуга күп вакыт бүлә. Быелгы уку елында 9нчы сыйныфта укучы талантлы кыз район күләмендә җиңүче булып, Уфада узган татар теле һәм әдәбияты олимпиадасында да яхшы күрсәткечләр белән катнашты. Анда катнашучылар санын исәпкә алганда да, минемчә, укучы өчен бу — зур җиңү. Киләчәктә дә зур уңышлар сиңа, Айлина!

### *Өлгер кыз Ильвина*

10 “б” сыйныфта белем алучы өлгер кыз Ильвина Гайнуллинаның булдыклы, уңган һәм бик сәләтле укучы булуы турында укытучылары илһамланып сөйләде. Гел елмаеп кына торучы матур кызның мәктәптә узган конкурсларда, район күләмендәге олимпиадаларда җиңү яулавына һич аптырарлык түгел. Ул анда сәнгатьле сөйләү, җыр буенча осталыгын да, күп эшләрендә үзенә тиңнәр юклыгын да, белеме тирән булуын да ачык күрсәткән. Тугызынчы сыйныфны гел “4ле” һәм “5ле” билгеләренә генә тәмамлаган Ильвина, узган уку елында ук фәнни конференциядә катнашып, үзенең эшен уңышлы яклап чыккан.

## *Сурәтләрендә - кояш нуры, зәңгәр күк йөзе*



Укучыларда сәнгатькә карата кызыксыну тәрбияләүдә лицеебызның талантлы укытучылары Усманова Римма Галимҗан кызы һәм Габидуллина Раушания Фирдәвес кызының роле зур. Бала бөтен күңелен, игътибарын рәсем төшерүгә биргән. Ак кәгазь битендә аның күңелендә туган фантазияләре чагылыш таба. Җанварлар, кешеләр, табигать күренешләре... Каян килгән мондый сәләт-бүләк?! Башкалар сыман уенчыклар, иптәшләр белән уен да кирәкми, бары тик кәгазь-каләм генә бирегез аңа!




... Арсен Нагаев өч яшеннән рәсем төшерә башлый, кечкенә бармаклары белән пластилиннан төрле сыннар әвәли. Вакытны онытып, бар булмышы белән шул дөньяга чума. Мөгаен, ул бабасының рәсем төшерүен, агач эшләре белән шөгыльләнүен күреп, кул эше белән кызыксынгандыр. Арсенның сәләтен күргән әнисе, укытучысы, картәтисе вакытын кызганмый - әнисе аны төрле түгәрәкләргә йөртә башлый: башта мәктәптәге, аннары район мәдәният сараендагы төрле түгәрәкләргә яздыралар. Арсен кечкенә чагында ук акбур белән тактада рәсемнәр төшереп булаша. Балалар бакчасында тәрбияче ныкышмалы, эшен ахырына җиткерергә яратучы тырыш кызчыкны игътибарыннан читкә җибәрми, бераз үсә төшкәч, түгәрәктә шөгыльләнергә чакыра. Арсенның рәсемнәреннән балалар бакчасының музеенда күргәзмә оештыралар.

Бүгенге көндә укучыларыбыз Руфина Ягафарава, Ранис Морзагилдинның эшләре бөек язучы Галимҗан Ибраһимовка багышланган конкурста катнашты һәм җиңеп чыкты – “Карт ялчы”, “Кызыл чәчәкләр”, “Татар хатыны ниләр күрми” әсәрләре буенча төшерелгән рәсемнәр район китапханәсендә күргәзмәгә куелган. Талантлы кызларыбызның эшләре белән район халкы да таныша башлый. Шулай ук, Римма Галимҗан кызы Эльвина Батыршина , Рушана Вәлиева, Аделина һәм Риваль Гыйләҗетдиновларның эшләрен мактап туя алмый. Киләчәктә уңышлар сезгә, яшь рәссамнар!

# *Яшьтәшләре үрнәк алсын...*

Сер түгел, хәзер югары уку йортларына укырга керү күпкә җиңеләйде. Мондый үзгәрештә демографик хәлдән тыш, бердәм дәүләт имтиханы да сәбәпче. Шулай да, тырышлыгың, максатыңа омтылышың булмаса, уңышка ирешә алмыйсың. Димәк, уку йортларында конкурс чагыштырмача аз булса да, укучыларга элеккечә тырышып укырга кирәк. Безнең лицейда мондый укучылар байтак. Гадәттә, сәләтле кеше бер өлкә белән генә чикләнми.

Быел мәктәпне тәмамлаячак Алмаз Ихтисамов да шундыйлар исәбенә кертергә мөмкин. 2016-2017 уку елы аның өчен уңышларга шактый бай булган. Эмиль экономика буенча район олимпиадасында беренче урын алган. Республикада да сынатмаган. Уфадан призлы урын яулап, яңа дуслар табып кайткан. — Әлбәттә, уңышка ирешү өчен җитди әзерләндем, — ди ул. — Чөнки миңа, гади авыл егетенә махсус белем бирелгән гимназияләрдә, лицейларда укучылар, югары уку йортлары профессорлары кулы астында шөгыльләнүчеләр белән көч сынашырга туры килде. Биремнәр шактый авыр иде. Укытучым белән көн-төн гыйлем дөньясында гизгәнгә, сынатмадым. Республика олимпиадасындагы призлы урын минем өчен яңа мөмкинлекләр ача. Студент була алу мөмкинлегем арта. Шатланырга иртә әле. Алда яңа сынаулар көтә. БДИга җитди әзерләнеп, югары баллар җыярга кирәк.

- *Мәктәп юлы — мәңгелек.*
- *Китап — тормыш көзгесе.*
- *Китап — якын сердәш.*
- *Күп беләсе килгән кеше күп йокламый.*
- *Надан кеше сукырдан яман.*
- *Уку — энә белән кое казу.*
- *Белем — бәхет ачкычы.*
- *Дөньяда иң изге урын — мәктәп, иң зур байлык — белем.*

## *Мәзәкләр.*

*   *   *

*Укытучы аңламый.*

*— Ни булды сиңа, улым, тагын икеле алгансың,—ди Әхмәтнең әнисе.— Бәлки син укытучының соравын аңламыйсыңдыр?*

*— Киресенчә, әни,— ди Әхмәт,— сорауларны мин бик яхшы аңлыйм, ә укытучы үзе минем җавабымны аңламый.*

*   *   *

*Соң түгел.*

*— Әхмәт, ник син мәктәпкә гел соңарып киләсең?*

*— Укырга беркайчан да соң түгел, диләр ич, апа.*

*   *   *

*Ата: — Менә сиңа яңа сумка алдык, Әхмәт, син шуны тутырып бишлеләр генә алып кайт.*

*Әхмәт: — Ә китапларны кая салырмын?*

***26 апрель – Габдулла Тукайның туган көне.***

***26 апрель – Габдулла Тукайның туган көне.***

## ***Без — Тукай оныклары***



***Тарих бик күп исемнәрне белә,***
***Бөек исемнәргә дөнья бай.***
***Сәнгать дөньясында маяк булып,***
***Мәңге яши, яшьни яшь Тукай!***

2011 ел ЮНЕСКО карары белән төрки дәүләтләрдә “Тукай елы” дип игълан ителде. Бу очраклы хәл түгел. Чөнки Габдулла Тукай — татар халкының гына бөек шагыйре түгел, ә бөек зат. Габдулла Тукайның тууына 130 ел тулу Татарстанда һәм Башкортстанда, Русия Федерациясенең бик күп төбәкләрендә киң билгеләп үтелде.

Юбилей чаралары вакытында Казанда, Санкт-Петербургта, Мәскәүдә, Уральскида, Әнкарада бөек шагыйрьгә һәйкәлләр ачылды.

“Кызыл таң” гәзите редакциясе күптән түгел үткәргән “түгәрәк өстәл”дә Уфада да Габдулла Тукайга һәйкәл булырга тиешлеге хакында сүз кузгатылуын да бик урынлы дип исәплибез. Беренчедән, республиканың яңа Президенты Рөстәм Хәмитов Уфада һәйкәлләр аз булуына игътибарыбызны юнәлтте. Икенчедән, Тукайның башкорт шигърияте белән ихлас кызыксынуы билгеле. Өченчедән, май аенда Тукайның Уфага килүенә 105 ел тула. Мәҗит Гафури белән дуслыгы ике әдәбиятны, ике халыкны берләштерүче, якынайтучы тарихи сәхифә булып тора.

“Кызыл таң” башлаган бу эшнең тиздән нәтиҗәсе дә күренде. Башкортстан татарларын шатландырып, Уфа шәһәре администрациясе 26 нчы октябрьдә бөек Тукайга һәйкәл куелачагы турында карар кабул итте һәм карарда булачак һәйкәлнең урынын да игълан итте. Ул “Нур” театры каршында урын алачак.



# *Викторина сораулары*

1. Тукайның туган авылы?
2. “ Кызыклы шәкерт ” шигырендәге этнең исеме?
3. Габдулла Тукай туган ел?
4. Тукайның әнисе нинди авылга кияүгә чыга?
5. Су анасының югалткан әйбере?
6. Безнең Гали бигрәк тату нәрсә белән?
7. Сандугач белән сөйләшкән кызның исеме?
8. Кәҗә белән сарык нәрсә пешерәләр?
9. “ Шүрәле ” әкиятендәге егетнең исеме?
10. Тукай үлгән ел?
11. Габдулланы әнисе нинди карчыкка биреп калдыра?
12. “ Шүрәле ” дә нинди авыл табигате сурәтләнгән?
13. Кәҗә белән бик тату малайның исеме?
14. Шагыйрь үлгән шәһәр?
15. Фатыйма нинди кош белән сөйләшә?
16. Бүре башын кемнәр тапкан?
17. Кайсы шигырь артык?
    1. “ Бала белән Күбәләк ” 2. “ Кызыл ромашка ”
    3. “ Гали белән Кәҗә ” 4. “ Буран ”
18. Кайсы әкият Габдулла Тукайның иҗатына туры килми?
    1. “ Сертотмас үрдәк ” 2.” Шалкан ”
    3. “ Су анасы ” 4. “ Кәҗә белән Сарык ”
19. “ Эш беткәч уйнарга ярый ” шигырендә бала янына нәрсә килми?
    1. Кояш 2. Эт
    3. Сандугач 4.Алмагач

# *«Ашханәгә сәяхәт»*

Безнең татар халкы әвәледән үк тәмле ризыклары белән дан тотканнар. Алар итле ризыкларны һәм камыр ашларын бик оста, тәмле пешергәннәр. Без сезнең белән көн дә иртән, көндез, кичен тәмле-тәмле ашлар, ризыклар ашыйбыз, ә менә мәктәптә шул тәмле ашларны кем пешерә икән, шуны белмибез. Шуңа күрә бүгенге кызыклы сәяхәтебез мәктәп ашханәсенә булыр. Балаларга апрель аеннан мәктәп ашхәнәсендә бигрәк тә ошый.

- Исәнмесез, апалар. Без сезгә бүген сәяхәткә килдек, балаларның тәмле ризыкларны кем пешергәнне һәм ничек пешергәнне күрәселәре килә.

- Исәнмесез, балалар. Без сезгә бик шат, әйдәгез, түрдән узыгыз, дип каршы алалар, тәмле ризыклар белән туклandыралар безне.



- **Аш дигәндә - ашыгыр, эш дигәндә - башын кашыр.**
- **Аш дигәндә - җан-фәрман, эш дигәндә - юк дәрман.**
- **Аш янында ат кебек, эш янында эт кебек.**
- **Ашаганда мин телсез, эшләгәндә мин өнсез.**
- **Ашка дисәң - Зәбидә, эшкә дисәң - юк өйдә.**
- **Ашаган белми, тураган белә.**
- **Ашаганда колагың селкенсен, эшләгәндә йөрәгең җилкенсен.**
- **Ашаган малда өмет бар.**
- **Ашап туймаганны, ялап туймассың.**
- **Ашау эшне калдырмый (, кашык кулны талдырмый).**
- **Ашка каршы - аш, ташка каршы - таш.**
- **Ашлаган җир аш бирер.**
- **Ашыккан - ашка пешкән.**

Чыгарылышны татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Г.М. Шәяхмәтова әзерләде.